ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14 ноябрь, 2025 ел № 2/9

Шәһәр Советының даими комиссияләре турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы Регламенты нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2011 елның 26 маендагы 12/8 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының даими комиссияләре турында Нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2014 елның 10 июлендәге 31/22, 2015 елның 17 декабрендәге 4/14, 2018 елның 10 августындагы 26/15, 2019 елның 23 маендагы 31/14, 2023 елның 3 ноябрендәге 9/7, 2024 елның 25 гыйнварындагы 30/7 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 6 статьяның бишенче абзацын түбәндәгечә бәян итәргә: «Даими комиссия даими комиссия әгъзалары арасыннан даими комиссия рәисе урынбасарын сайлый, аның кандидатурасын даими комиссия рәисе фикер алышуга куя»;

2) 10 статьяда:

- икенче абзацны яңа редакциядә бәян итәргә: «-шәһәрнең социаль-икътисадый үсеше стратегиясен раслау;»;

- өченче абзацта «аның үтәлешен контрольдә тоту» сүзләрен төшереп калдырырга;

- дүртенче абзацны төшереп калдырырга;

- 12 абзацны «-авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерү,» сүзләре белән тулыландырырга;

3) 12 статьяда:

- түбәндәге эчтәлектәге 24 абзац өстәргә:

«-Башкарма комитет Җитәкчесе белән берлектә референдум үткәрү инициативасы белән чыгу;»;

- 25 абзацта «уздыру» сүзен «уздыру инициативасы белән чыгу һәм бмлгеләү» сүзләренә алыштырырга;

4) 13 статьяда:

-7 абзацны төшереп калдырырга;

- 8 абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

«-халыкның мәшгульлеген тәэмин итүдә катнашу;»;

5) 14 статьяда

- 3 абзацны яңа редакциядә бәян итәргә: «- шәһәр территориясендә балаларга өстәмә белем бирүне һәм һәркем өчен мөмкин булган мәктәпкәчә белем бирүне оештыру, муниципаль мәгариф оешмаларында спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программалары буенча балаларга өстәмә белем бирүне оештыру;»;

- 13 абзацны яңа редакциядә бәян итәргә: «муниципаль милектәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрне) саклау, алардан файдалану һәм популярлаштыру;».

6) 29 статьяны яңа редакциядә бәян итәргә: «Даими комиссия утырышлары беркетмәләрен даими комиссия рәисе имзалый.»;

7) 31 статьяның бишенче абзацында «Даими комиссияләрнең берләштерелгән утырышлары беркетмәсен тиешле даими комиссияләр рәисләре һәм секретарьләре имзалый» җөмләсен яңа редакциядә предложением в новой редакции «Даими комиссияләрнең берләштерелгән утырышлары беркетмәсен тиешле даими комиссияләр рәисләре имзалый».

2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев